КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 19 июль г.Казань № 604

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталар һәм транспорт кушымтасы булган электрон карталар бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 2 июль, 574 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2071 ел, 6 ноябрь, 844 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «пассажирлар транспортының барлык төрләрендә» сүзләрен «җәмәгать транспортының барлык төрләрендә һәм шәһәр яны элемтәсендәге автомобиль транспортында» сүзләренә алыштырырга;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары белән берлектә, 2019 елның 1 октябреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының Әгерҗе, Азнакай, Аксубай, Актаныш, Алексеевск, Әлки, Апас, Арча, Әтнә, Баулы, Балтач, Бөгелмә, Буа, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Алабуга, Зәй, Кайбыч, Кама Тамагы, Кукмара, Лаеш, Лениногорск, Мамадыш, Менделеевск, Минзәлә, Мөслим, Яңа Чишмә, Нурлат, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Сарман, Спас, Тәтеш, Тукай, Чирмешән, Чистай һәм Ютазы муниципаль районнарында законнар нигезендә җәмәгать транспортының барлык төрләрендә һәм шәһәр яны элемтәсендәге автомобиль транспортында йөрүгә түләү буенча автоматлаштырылган система операторларын сайлап алу эшен үткәрергә.»;

5 нче пунктның өченче абзацында «2012 елның 1 сентябреннән» сүзләрен «2020 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталар һәм транспорт кушымтасы булган электрон карталар бирү тәртибенең 4 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталарны бирү пунктларында ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталарны рәсмиләштерү һәм бирү турында гаризалар кабул итүне оештыруны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре гамәлгә ашыра.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юл йөрү өчен ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталардан һәм транспорт кушымтасы булган электрон карталардан файдаланып түләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 апрель, 161 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2012 ел, 17 сентябрь, 772 нче карары белән расланган Юл йөрү өчен ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталардан һәм транспорт кушымтасы булган электрон карталардан файдаланып түләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Карталар уң ягында хуҗасының фамилиясе һәм исеме язылган контактсыз банк карталарын кулланып башкарылырга мөмкин. Контактсыз банк картасында башкарылган ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон картадан файдаланганда, карта хуҗасының шәхесен һәм ташламага хокукын раслый торган документны күрсәтү таләп ителә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин